| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ |
|---|---|---|
| **Исполнительный комитет Аксубаевского муниципального района** | | **Аксубай муниципаль районы башкарма комитеты** |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

« 07 » 05 2020 № 269

Аксубаево

Аксубай муниципаль районы Башкарма комитетының «Административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзергә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеген билгеләү турында» 2016 елның 9 февралендәге 37 нче номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексына һәм «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзергә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеген билгеләү буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү хакында» Татарстан Республикасы Законының 1 маддәсенә үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 23 апрелендәге 17-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын үтәү йөзеннән, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Башкарма комитеты
КАРАР БИРӘ:

1.Аксубай муниципаль районы Башкарма комитетының «Административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзергә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеген билгеләү турында» 2016 елның 9 февралендәге 37 нче номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2. Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Башкарма комитетының Административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзергә вәкаләтле вазыйфаи затлары исемлегенең 1 нче кушымтасын түбәндәге эчтәлекле 21 пункты белән тулыландырырга:

| | | |
|---|---|---|
| 21 | 2.17 нче маддә. Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексы.<br><br>Яңа коронавирус йогышы (COVID-19) таралуын | Аксубай муниципаль районы Башкарма комитетының икътисад бүлеге начальнигы<br><br>Аксубай муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлеге начальнигы |

| | | |
|---|---|---|
| | булдырмый калуга һәм бетерүгә юнәлдерелгән Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары таләпләрен үтәмәү. | Аксубай муниципаль районы Башкарма комитетының Яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге начальнигы,<br>Аксубай муниципаль районы Башкарма комитетының опека һәм попечительлек бүлеге начальнигы<br>Аксубай муниципаль районы Башкарма комитетының «Мәгариф бүлеге» МКУ начальнигы,<br>Аксубай муниципаль районы Башкарма комитетының «Мәдәният бүлеге» МКУ начальнигы<br>Аксубай муниципаль районы Башкарма комитетының Архив бүлеге начальнигы,<br>Юл хәрәкәте иминлеге өлкәсендә җәмәгать тәртибен саклау пунктлары эшчәнлеген тәэмин итүче әйдәп баручы белгеч.<br>Балигъ булмаганнар арасында гаилә иминлеге һәм җинаятьләрне профилактикалау өлкәсендә әйдәп баручы белгеч<br>Коррупциягә каршы тору мәсьәләләре буенча район башлыгы ярдәмчесе (килешү буенча).<br>Аксубай муниципаль районы Советының Җирле үзидарә органнары белән хезмәттәшлек итү һәм методик-мәгълүмат эше бүлеге башлыгы (килешү буенча).<br>Шәһәр һәм авыл җирлекләре башкарма комитетлары җитәкчеләре (килешү буенча) |

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга: http://Aksubayevo.tatarstan.ru.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Аксубай муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктур үсеш буенча урынбасары И.И. Исламовка йөкләргә.

Татарстан Республикасы

Аксубай муниципаль районы

Башкарма комитеты җитәкчесе А. Ф. Горбунов